www.assalam.ru
www.islamdag.ru
assalamweb@gmail.com

12+

# ӘС-СӘЛӘМ

ДИН-МӘГЪРИФӘТ ГАЗЕТАСЫ

Бәясе иркле

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ МАКТАУЛАР БУЛСЫН!

Җөмадиәләүвәл 1438 ел. 1994 нче елдан бирле бастырыла. № 2 (03) / 15 февраль 2017 ел.

## Шәех Зәйнулла Рәсүли

МӘСГУД ГӘЙНЕТДИНОВ

Бу мәкаләдә мәрхүм филология фәннәре докторы һәм тарихчы Мәсгуд абый Гайнетдинов Зәйнулла ишан Рәсүли тормышы турында яза.

Революциягә кадәрге соңгы 45 елда татарлар арасында иң күренекле шәхесләрнең берсе Зәйнулла ишан булган дисәк, ялгышмабыз. Каләм тибрәткән, язган дүрт-биш китабы булган диләр. Әмма язганнары үз вакытында ук ишетелмәстән, күренмәстән диярлек калганнар. Шаулы шөһрәтен ул иҗтимагый хәрәкәттә үзенә бер юнәлеш тотуы белән һәм шәехлек-суфилык (ишанлыгы) белән казана.

Зәйнулла бине Хәбибулла, бине Рәсүл, бине Муса, бине Бәйрәмкол, бине Гашыйк, бине Солтанай, бине Морадкабул, бине Тулай, бине Уразгали, бине Яңшый, бине Яты би – шундый шәҗәрәләре сакланган. Яты би – Алтын Урда биләреннән берсе булуы ихтимал.

Зәйнулла хәзрәт 1833 елда Оренбург губернасы Троицкий өязендәге Шәрип исемле авылда дөньяга килә. Башлангыч белемен үз авыллары мәктәбендә ала. 1845 елда авылларыннан 15 чакрымдагы Малай Муйнак авылындагы Якуб хәзрәт мәдрәсәсенә укырга китә. 1848 елда Якуб хәзрәтне Уралдагы Ахун авылына имамлыкка чакыралар. Шәкертләре дә аңа ияреп Ахун авылына китәләр. 1851 елда Зәйнулла Троицкий шәһәрендәге Әхмәт Халид улы Мәңгәри мәдрәсәсенә күчә. 1858 елга кадәр шунда укып мадрәсә курсын тәмамлый.



1858 елда яшь Зәйнулланы Югары-Урал өязендәге Акхуҗа дигән типтәр авылына имамлыкка чакыралар. Шунда ук, мәктәп оештырып, имамлыгы белән бергә, балаларны укыта башлый. Өйләнә. Шәкертлек елларында ук суфичылык-тарикатькә тартыла башлаган кеше, 1859 елда, Габделхәким Чардаклыви дигән ишанга «кул биреп» – мөрид булып, ишанлык сабаклары ала башлый. 1866 елга хатыннары санын дүрткә җиткерә.

Гаилә ишәйгәч, көнкүреш кимчелекләрен капларга дип, сәүдә эшенә керешеп карый, ләкин ике елдан сон, бөлгенлеккә төшеп, бу эштән читләшергә мәҗбүр була. Мәккәгә барып, хаҗ фарызын үтәү турында хыяллана. Һәм, ниһаять, бу максатына ирешә. Вафат булган бер казак бае үзе өчен хаҗ фарызын үтәргә акча калдырган икән, бәдәлче (ялланып хаҗга баручы) булып барырга Зәйнулла хәзрәткә тәкъдим итәләр. Шул рәвешчә, ул 1869 елда хаҗ сәфәренә чыга. Шул көннән, хәзрәт тормышында яңа этап башлана.

Яңа заман кешесе – яшь Зәйнулла хәзрәтне шул заман тормышындагы гадәти булып калган ишанлык ысулы канәгатьләндермәгән, күрәсең.

6НЧЫ БИТ

НӘСЫЙХӘТ

## Калеб хәзинәсе

Укучыларыбыз игътибарына «Күңелләр дәвасы» китабыннан Фәния ханым Җәләлиеваның бер язмасын тәкъдим итәбез.

Хөрмәтле дин кардәшем! Ошбу хезмәтебезне Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафанән (салләллаһу галәйһи вәссәллам) үк килгән, олы галимнәр тарафыннан дәвам иттерелгән тарикать юлы белән кызыксынучыларны күздә тотып яздык.

Шушы юлга керергә теләүчеләргә беренче адымнарны тәкъдим итәбез. Суфичылык юлына мәхәббәтле булучыларга кулланма дип әзерләдек.

7НЧЫ БИТ

ГЫЙБАДӘТХАНӘ

## Мөселманда хатын-кыз

Бүген кайсы диндә хатын-кызның хокуклары кимрәк дигән сорау куйсак, һичшиксез, күпчелек кеше ислам динендә дип әйтәчәк. Моның сәбәбе – ислам дине дошманнарының гасырдан артык мөселман хатыннарының хокуклары бозылуы турында чаң кагуларында. Ә без шул көчләп тагылган фикерләр белән эш итүебез аркасында Аллаһы Тәгалә биргән көч-кодрәтебезне югалттык та инде. Көндәлек тормышыбызда дин күрсәтмәләрен үтәмибез. Тормышыбыз, гаиләләребез Көнбатыш илләре үрнәгендә җайланган.

4НЧЫ БИТ

## Файдалы очрашу

ФӘНИЯ ҖӘЛӘЛИЕВА

Гыйнвар аенда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең читтән торып уку бүлеге шәкертләренең кышкы сессиясе тәмамланды. Шәкертләр Татарстан Диния нәзарәте вәкилләре, галимнәр, зыялылар белән очраштылар.

Мәдрәсәбездә күп еллардан килгән күркәм гадәт бар. Республикабыз район-авылларыннан, Россиянең татарлар яшәгән чит төбәкләреннән шәкертләр сессиягә килгәч, күренекле шәхесләр белән очрашулар уза.



Үз вакытында мондый очрашулар милләтебез зыялылары – күренекле драматург Туфан ага Миңнуллин (1935-2012), танылган шагыйрь Разил Вәлиев, атаклы галимнәребез Яхъя Абдуллин (1920-2006), Мирза Мәхмүтов (1926-2008), Равил Үтәбай-Кәрими (1933-2005), Миркасыйм Госманов (1934-2010), Әнвәр Хәйри (1947-2014), Марсель Әхмәтҗанов, халкыбыз сандугачлары Илһам Шакиров, Миңгол Галиев белән узган иде.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең уку-укыту эшләре буенча урынбасары Рәфыйк хаҗи Мөхәммәтшин белән узган очрашуда сүз ислам мәгарифенең хәзерге торышына бәя бирүдән башланды. Ул шулай ук быел бинасы төзелеп бетеп ачылырга ниятләнгән Болгар ислам академиясен булдыруның кирәклеге турында сөйләде. 2016 нчы ел ахырында ТР Фәннәр академиясе академигы булып сайланган Рәфыйк Мөхәммәтша улы шулай ук халкыбызда ислам фикере үсеше тарихына да тукталды.

БИТ 2

### Татарстан Президенты, Мөфти гомрә хаҗын кылды



2НЧЫ БИТ

### Мәдрәсәләребез — «татар академияләре»



4НЧЫ БИТ

### Иман һәм гамәлләр



4НЧЫ БИТ

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

## Татарстан Мөфтие Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә мөгаллиме Наил Таировны медаль белән бүләкләде

Бүген Диния нәзарәтендә тарих фәннәре докторы, доцент, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә мөгаллиме Наил Измаил улы Таировка махсус медаль тапшырылды. Мөгаллимне «Халкыбызга хезмәт өчен» медале белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе бүләкләде һәм рәхмәт сүзләрен ирештерде. «Аллаһы Тәгалә һәр эшегездә сезгә Үзенең бәрәкәтен һәм өммәтебезне рухи яктан ныгытуга, аны гыйлемле итүгә керткән эшчәнлегегез өчен әҗер-савапларын бирсен», – дип теләде Камил хәзрәт.

Наил Исмәгыйль улы Таиров – профессор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Ул заманында Ульяновск дәүләт педагогия институтын тәмамлаган. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә 1998 елдан бирле «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» буенча чыгышлар ясый.

Тантаналы чарада мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин да катнашты.

## Азнакайда Коръәнне яттан уку буенча «Әсләм» республика бәйгесе үтте

Азнакайда Коръәнне яттан уку буенча «Әслэм» республика бәйгесе үтте, дип яза районның «Маяк» газетасы.

Бәйгенең символик исеме «Әслэм» булуы юкка гына түгел. Аны әтиләре – район үсешенә зур өлеш керткән эшмәкәр, милли көрәш буенча спорт остасы Әслэм Шакиров истәлегенә уллары үткәрде.

«14 ел дәвамында әтиебез истәлегенә көрәш турниры оештырып, җиңүчеләргә өч ел рәттән хаҗга юллама бирдек. Быел исә уйлаштык-уйлаштык та, әтиебезнең рухына багышлап, Коръән уку бәйгесен үткәрергә ниятләдек. Бәйгенең максаты – изге китапны дөрес итеп укуга, аны өйрәнүгә булган омтылышны тагын да көчәйтү, динебезгә мәхәббәт тәрбияләү», – ди Рөстәм Шакиров.

Бәйгедә башкалабыз Казаннан да биһисап кунаклар катнашты, алар арасында республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин да бар иде.

Бу көнне бәйгегә республиканың кайсы почмагыннан гына килмәгәннәр: Әгерҗе, Кукмара, Буа, Биектау һ.б. районшәһәрләрдән барлыгы 19 кеше Коръәннең соңгы өч өлешен яттан сөйләү буенча үз осталыкларын күрсәтте. Алар арасында балаларның да булуы – аеруча куанычлы.

Әнә, Биектау районыннан килгән Мөхәммәт Йосыпов чыгыш ясаганда, аңа сокланмаган кеше калмагандыр! 9 яшь кенә булса да, жюри әгъзаларының һәр соравына шартлатып җавап бирде ул.

Бәйгедә безнең район данын Исмәгыйль Зарипов яклады. 27 яшьлек егет изге китапның 10 өлешен яттан белә.

«Беренче карашка гына Изге Коръәнне ятлау мөмкин түгел кебек тоела. Әмма Аллаһы Тәгалә җиңеллеген бирә ул. «Бер генә китап та Коръән ятланган кебек ятланмый. Бу – аңа Аллаһ тарафыннан бирелгән үзенчәлек, ул аны шуның белән башка китаплардан аерып тора» диелгән хәдистә дә», – ди якташыбыз.

Бәйге шартлары буенча, 1нче һәм 2нче урыннарны яулаучыларга Шакировлар гаиләсе олы хаҗга һәм гомрә хаҗына ике юллама әзерләгән иде. Бу көнне үзләренең исемнәрен белгесез итеп калдырырга теләгән ике якташыбыз моңа кадәр хаҗга бармаган ике кешегә юлламалар бүләк итте. Шулай итеп, Коръәнне яттан сөйләү буенча республика бәйгесендә беренчелекне алган Нияз Минсабиров (Әлмәт), Эрнест Нәфыйков (Түбән Кама), Рамазан Идрисов (Зәй) олы хаҗга юлламалар отты.

Әгерҗе районыннан Мөхәммәтгали Корбановка гомрә хаҗына бару бәхете елмайды. Казан шәһәреннән килгән 12 яшьлек Инсаф Вәлиев район башлыгы Марсель Шәйдуллин кулыннан кыйммәтле бүләк – ноутбук алды, диелә район газетасы хәбәрендә.

# Татарстан Президенты, Мөфти гомрә хаҗын кылды



Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанына эш сәфәре кысаларында кече хаҗ кылды. Президент белән бергә әлеге олы гыйбадәтне мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да башкарды.

Шуны да әйтергә кирәк, Татарстан вәкилләре Согуд Гарәбстанының бары шәрәфле кунаклары гына керә торган Кәгъбә эченә дә керделәр.

ХАҖ

Хаҗ – исламның бишенче шарты. Ягъни матди мөмкинлеге житкән мөселманга гомерендә бер мәртәбә булса да Мәккәгә, Кәгъбәгә бару фарыз.

Бу матди һәм физик мөмкинлекләре булган һәр мөселман гомерендә бер тапкыр Зөлхиҗҗә аенда Мәккәгә хаҗга барырга тиеш дигән сүз. Мәккә – мөселманнарның Гарәп ярымутравында урнашкан изге шәһәрләреннән иң әһәмиятлесе.

Хаҗ берничә төрле йоладан гыйбарәт: аңа ихрам (хаҗ киемнәрен) кию, Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында тору, Кәгъбәтулланы җиде мәртәбә әйләнү, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөрү, таш ату, корбан чалу һәм башкалар керә. Хаҗ гамәлләре башкарыла торган һәр урын нинди дә булса тарихи вакыйга белән бәйле, хаҗ йоласының һәркайсының аерым мәгънәсе һәм тарихы бар.

Хаҗ гамәлләрен үтәгәндә барлык кешеләр дә – хуҗа һәм хезмәтче, хөкемдар һәм гади кеше бертигез дәрәҗәдә була. Бай һәм ярлы ир-ат мөселманнар бертөрле кием кия, ягъни ике кисәк ак тукымага төренәләр.

Хаҗ иманлы кешеләргә Кыямәт көнен искәртеп тора, ягъни бу көнне барлык кешеләр дә Аллаһы Тәгалә каршына ялангач килеп басып, дөньялыкта кылган гамәлләре өчен җавап тотачаклар. Кыямәт көнендә кешегә аның чыгышы да, гомере буена туплаган мал-мөлкәте дә, җәмгыятьтәге урыны да ярдәм итмәячәк.

Хаҗ кылу һәр мөселманның тормышында мөһим вакыйга, гөнаһларның ярлыкануына ирешү, тормышыңны яңадан кузаллау һәм яхшыга таба үзгәртү мөмкинлеге ул.

Гомрә – хаҗ кылу вакытыннан башка елның теләгән көнендә хаҗ кылу. Гомрә хаҗын гомердә бер тапкыр башкару – сөннәт гамәл.

Гомрәнең гамәлләре өчәү: тәваф кылу (Кәгъбәтулланы 7 тапкыр әйләнеп чыгу), сәгый кылу (Сафа белән Мәрва таулары арасында 7 тапкыр үтү) һәм чәчне алдырып яисә кыскартып, ихрамнан чыгу. Олы хаҗда исә бу гамәлләрдән башка, Мина тарлавыгында булу, Гарафәттә тору, төнен Мөздәлифәдә куну, Минада яшәү, «шайтанга таш ату» йоласын үтәү, корбан чалу гамәлләре дә өстәлә.

# Файдалы очрашу

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

Аерым алганда, Шиһабетдин Мәрҗани, Габдерәхим Утыз Имәни, Ризаетдин Фәхретдин кебек олуг татар дин галимнәренең зур рухи мирасын өйрәнү, белү мөһимлеген ассызыклап, нотык тотты. 2017 елның Татарстанда Галимҗан Баруди елы дип билгеләнүе турында белдереп, шушы мәшһүр дин галименә багышлап узачак чаралар белән таныштырды. Шулай ук Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның, Россия ислам институты мөгаллимнәренең Сүрия дәүләтенә сәфәре барышында Шиһабетдин Мәрҗани мирасына карата чит җирләрдә игътибарның зур булуы белән танышып кайтулары турында җиткерде, татар дин галимнәре мирасының мөселман дөньясында киң кулланылышта булуын әйтте.

Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев белән очрашу да мәгълүмати яктан бик бай эчтәлекле булуы белән үзенчәлекле булды. Җәлил хәзрәт авылда имам-хатыйб булып эшләүнең кайбер нечкәлекләре хакында бәян кылды һәм диннең торышына бәя биргәндә нәкъ менә имамчылык итүченең шәхесенә карап бәя бирелүен ассызыклап үтте. Ул шулай ук динебездә мөһим булган дүрт кагыйдә белән таныштырды, Аллаһы яратткан бер мәхлукатны да сүкмәскә өндәде. Шулай ук бер-береңне гафу итүнең, күркәм холыклы, әдәпле булуның динебездә бик зур урын тотуына тукталды. Вәгазьләргә яхшылап әзерләнергә кирәклегенә игътибарны юнәлтте һәм халык белән очрашу барышында сорауларга җавап бирер өчен күп кызыксынырга, күп яктан мәгълүматлы булырга кирәклегенә басым ясады.

12 гыйнвар көнне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр белән очрашу узды. Әлеге очрашуның төп темасы буларак традицион ислам төшенчәсе каралды. Шулай ук үз чыгышында Рөстәм хәзрәт «Нәрсә ул иман?» дигән сорауга, «Иман һәм гамәлләр» мәсьәләсенә аңлатма бирде, бүген Әбү Хәнифә мирасын өйрәнүнең зур әһәмияткә ия булуын ассызыклады. Чөнки үз хезмәтләрендә Әбү Хәнифә күп тапкырлар беркемне дә тәкфирләргә гаепләмәскә, фикер каршылыкларын Аллаһы хөкеменә калдырырга кирәклеге турында язып калдырган. Шәһре Болгарга юл тоткан сәхабәләр бабаларыбызга дини кануннарны ничек дөрес үтәргә икәнлекне генә аңлатып калмаганнар, килгәндә чалма, юл таягы һәм кара савыты белән килгәннәр. «Чалма ул – фани дөньядан мәңгелек тормышка күчәргә, Аллаһы Тәгалә белән очрашырга әзерлекне күрсәтә торган билге; юл таягы – тынычлык символы; кара савыты – гыйлемлелек билгесе», – дип аңлатты Рөстәм хәзрәт.




Мәдрәсәбез мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин очрашу кунагына борынгы татар шәмаиле бүләк итте. Рөстәм хәзрәт әлеге тарихи ядкарьнең Ислам мәдәнияте музеенда үз урынын табачагын ышандырып, бу кадерле истәлекне табып китергән шәкерткә зур рәхмәтләрен ирештерде.

Читтән торып уку бүлеге шәкертләренең буш вакытлары бик файдалы үтте. Тел гыйлеменә, татар халкы һәм Татарстан тарихына багышланган лекцияләрне Казан (Идел буе) федераль университетының Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбенең татар журналистикасы кафедрасы доценты Илһам хәзрәт Фәттахов һәм мәдрәсәбез мөгаллиме, тарих фәннәре докторы Наил Таиров укып китте. «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк. Халкыбыз тарихында, узган юлында сизелерлек эз калдырган шәхесләр хакында күбрәк белергә, аларның яшәү рәвешен, идеалларын аңларга тырышуыбыз табигый. Игелекле гамәлләр кылган, милләт, халык мәнфәгатьләрен алга куеп фидакарьләрчә көрәшкән бөек затлар онытылмый, соклану, горурлану уята. Уйландыра, игелекле гамәлләр кылырга рухландыра», – диде Наил хаҗи шәкертләр каршында чыгыш ясап. «Милли тормыш һәм дин» темасына фикер алышуда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев катнашты. Ул ел саен уздыру гадәткә кергән татар имамнары форумы эшчәнлегенә тукталды. Шулай ук эшмәкәрләр, татар авыллары тарихын язучылар, дин әһелләре белән эшләүнең үзенчәлекләре турында сөйләде. Очрашу ахырында һәрбер шәкерткә истәлек бүләкләре – «Казан утлары» журналының – Г.Тукайның тууына 130 ел тулуга багышлап чыгарылган, «Идел» журналының Бөтендөнья татар яшьләре форумы турында язылган саны һәм «Милләт» нәшриятында дөнья күргән «Казан татарлары. Казанские татары» (авторы Пётр Знаменский) китапчыгы тапшырылды. Кичке буш вакытларда мәдрәсәбез остазы Тимур хәзрәт Ибраһимов чалма чалу буенча мастер-класс күрсәтте. Яшь тарихчы, Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе урынбасары Айрат Фәйзрахманов Казанның Яңа бистә тарихы турында сөйләде, сакланып калган һәм юкка чыккан архитектура һәйкәлләре турында мәгълүмат биреп, аларның фотоларын күрсәтте, Яңа бистәгә багышлап эшләнгән презентация белән таныштырды. Мәдрәсәбезгә килеп, Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге мөдире Нияз хәзрәт Сабиров үрнәк вәгазь укыды һәм суфичылык тарикатьләре турында сөйләде. Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин авылларда имам-хатыйб, мөәззин булып эшләүче шәкертләр белән очрашты, аларның сорауларына җавап бирде. Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе, җәмәгать эшлеклесе Фәрид Мифтахов, Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге вәкаләтле вәкиле Ренат Вәлиуллин милли оешмалар белән эшләү үзенчәлекләре турында сөйләде, тәҗрибәләре белән уртаклашты. Татар милли гореф-гадәтләрен саклап калу буенча фикер алышулар, сорауларга җавап бирү булды. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Айдар хәзрәт Кәрибуллин мәчеттә укытулар оештыру өчен программалар белән таныштырды. Ике атна җомгасында ике күренекле вәгыйзь Рөстәм хәзрәт Ясәвиев һәм Рамил хәзрәт Бикбаев вәгазь сөйләп, шәкертләр каршында җомга намазын укытты.

Мәдрәсәбездә үткән күркәм очрашулар, дәресләр, җомга намазлары читтән торып укучыларның күңелендә матур хатирә булып озак саклансын.

**НИЯЗ ХӘЗРӘТ САБИРҖАН**

мәдрәсәнең тәрбия эшләре буенча мөдир ярдәмчесе

# Сиринә Исмәгыйль кызы Шаһимәрдәнова: «Васыятеңне үтибез, әти!»

«И балалар, и туганнар! Берегезнең дә исемен әйтмәем. Барчагызга шуны әйтәм: үзегездән кечеләрнең килешмәгән эшләренә нык күзәтчелек итегез. Шулай балалар, Аллаһы риза булмаган эшләрдән бөтен көчегез белән сакланыгыз. Коръән кушканча яшәгез, чөнки безнең мәңгелек бәхетебез Коръән бит. Ягъни Коръән юлы гына безнең тугры юлыбыз. Коръәнгә ышанмаучыларга бик нык куркыныч». ...Саргаеп беткән дәфтәр битендәге әтинең кул җылысын, күз нурларын гына түгел, җан авазын саклаган әлеге юлларның язылуына 40 елдан артык вакыт үтсә дә, тыныч кына укып булмый.

Әтиебез Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшинның без, варисларына, атап язган ошбу васыятен күбәйтеп, барган бер җиремдә дин кардәшләремә, мәҗлестәшләргә таратуны гадәткә керттем. Балаларына атап әйтелсә дә, бүгенге көндә барыбыз өчен дә бик кыйммәтле нәсыйхәтләрен җиткергән, дөнья тормышында ничек яшәргә кирәклеге юлларының дин-исламыбызда булуын гади итеп, әтиләрчә аңлаткан. Тәрбияви ягы да, үрнәк итеп алып, үзеннең васыятьнамәнне булдыру өчен дә кабатланмас мисал бу. Ни кызганыч, күпләр васыятьнең нәрсә икәнен дә аңламый, аны мирас бүлү, гомер буе туплаган малны кемгә ничек өләшү хакындагы язу дип кенә уйлыйлар. Шөкер, әтинең дәфтәргә язып калдырган шактый озын васыятьнамәсендә мал-мөлкәт хакында сүз булмаса да, безгә бу фани дөньяда ничек яшәргә кирәклеге бәйнә-бәйнә аңлатылган. Аллаһны танып, олылап һәм Коръәни-Кәрим кушканча яшәргә чакырган әти.




Әти нәсыйхәтен ничек үтибез? Ул күрсәткән ак юлны без ничек уздык соң дип еш кына үз-үземә сорау куям да, җавап эзлим. Башкортстанның хәзерге Октябрьск каласыннан ерак булмаган Нарыш авылында безнең тамырлар. Биш бала үстек. Инде ике ир туганым һәм ике апам бакыйлыкка күчтеләр. Гаиләдә төпчек бала булып үскән миңа Аллаһы Раббыбыз бәрәкәтле, бәхетле гомер бирде. Әле шушы арада гына кадерлеләремне, дин-ислам юлында табышкан кардәшләремне 75 яшьлек гомер бәйрәмемә дәштем. Мәҗлесебезне улым Айдар Коръән укып башлады. Сөендем дә, дулкынландым да. Атеизм чәчәк аткан чорда үскән, дөньяви белемнәр алганнан соң, шактый зур үрләргә ирешеп, җаваплы вазифалар башкарган улымның дин-ислам юлын табуына, Аллаһка якынаюына һәм дә килеп, Исмәгыйль бабасының васыятен үтәвенә, лаеклы варис булуына дәлил түгелме бу?!

...Әти васыятен кулыма алган саен, соңгы елларда мине уйлар өермәсе бөтереп алды. Әти-әни мирасын берәмтекләп җыю, һәр икесенең нәсел шәҗәрәсен туплау булды хыялым. Мин моны башкарырга тиеш бурыч дип, намус эшем дип кабул иттем. Әтиебез Исмәгыйль Сәлимшаһ улы ягыннан 1700 елда Абдулкәримнән башланган нәселебезнең 10 буынын барладык. Әниебез Гайнелҗинан Сөләйман кызының 8 буынын ачыкладык. Берничә гасырда еракларга таралган нәсел тамырларын табуда зур тырышлык куелды.

Әти-әниләребез буынына дин кушканча яшәү, үзләре булып калу өчен бик катлаулы, алай гына да түгел хәтәр чорларның сынауларын үз башларыннан уздырырга туры килгән. Тарих – аерым шәхесләр, аерым кешеләр язмышы аша языла, диләр. Һәм килер буыннарга бу гыйбрәтле чорны әти язмышы аша күрсәтү нияте мине китап язарга этәрде. Мирасны берәмтекләп җыю һәм шул хәзинәне киләчәк буыннарга ирештерү өчен әтинең гаять бай кульязмаларын өйрәндем, байтак чыганаклар аша тарихи документлар таптым. Якташлар, туганнар, килер буыннар өчен Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин (1893-1975) исемен истә калдыру ниятенә керештем.

Китапка әтинең гомере буена халык өчен бик тә кирәкле, бик тә кадерле һөнәр иясе – тегермәнче булуы хакында авылдашларының җылы хатирәләре тупланды. 1950-1975 елларда туган авылы Нарышта имамлык итүе дәверендә якташларына ирештергән вәгазь-нәсыйхәтләре, фронт көндәлеге (1941-1945), шигъри әсәрләре, фәлсәфи уйланулары җыентыкта урын алды, һәм алар барысы да әтиебезнең нинди дә затлы, зыялы шәхес булуына ачык дәлил. «Дөнья – ахирәтнең игене, яки Нарыш җәүһәрләре» дигән әлеге шактый калын, татарча-русча китап-альбом яңа гына басылып чыкты. Мин аны үземнең гомер бәйрәменә бүләгем, минем шатлыгымны уртаклашучы нәселемә бүләк дип әзерләдем. Әлеге тарихи-документаль җыентыкның авторы үзем булсам, аны китап-альбом хәләнә китереп, укучыларга җиткерүне оештыручы мөхәррир – «Мирас» нәшрият йорты директоры Александр Долгов белән бизәлеш рәссамы Ратмир Әхиярова рәхмәт яусын, зур тырышлык куйдылар.

Дини тирән белемен дөньяви тормышта бергә оста үреп бара белгән, аны яшәү-эшләү рәвеше белән дәлилли алган гаять хөрмәтле Аксакал, абруйлы дин әһеле буларак гәүдәләнде Исмәгыйль хәзрәт. Китап-альбомны кулына алучыларга бирердә үрнәк өчен дә, фикерләү, чагыштыру һәм гыйбрәтләнү өчен дә дәлилле хикмәтләр җитәрлек. Әти-әниләребезнең, әби-бабайларыбызның бик авыр сынау-сыналу елларында да шәригатьне бозмыйча дөнья көткәннәре, ничек итеп динне саклап кала һәм безнең көннәргә китереп җиткергәннәре – үзе бер сабак.

Балаларыбыз, нәселебез дәвамчылары әти васыятенә тугрылыклы калырлар, ислам юлыннан, Аллаһы Тәгалә кушкан һәм Коръәндә күрсәткән юлдан аерылмаслар, мөселман исеменә тап төшермәсләр дигән өметтә калам. Гаиләмнең бүгенгесенә шөкер итәм. Ирем Равил Шаһимәрдәнов белән гаилә коруыбызга Аллаһ кушса быел 50 ел тула. Ике угыл үстердек, 7 оныгыбыз бар. Улларым, киленнәрем, оныкларым барысы да заманны, дөньяны сылтау итеп, төрле сәбәпләр тапмыйча, Аллаһны танып, динебез кушканча яшәүчеләр, Исмәгыйль бабалары васыятен үтәүчеләр. Шунысына шөкер итеп туймыйм.

**Язманы журналист ВӘСИЛӘ РӘХИМОВА әзерләде**

мәхәллә

# Күңелләргә шифа өләшә

...Җанланыйк, кузгалыйк һәр җирдә
Аллаһ гыйшкы хакына.
...Мәгърифәт, һөнәр туамы?
Бар да Аллаһ гыйшкы хакына.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның мәгълүм «Таян Аллага» шигырен эшләү-яшәү шигаре итеп алган дин кардәшебез Фәния абыстай Җәләлиеваның әле яңа гына «Күңелләр дәвасы» дигән дини, тарихи-публицистик китабы «Идел-пресс» нәшриятында табадан төште. Зикерләр, истәлекләр дип тәкъдим итә аны автор.

Яхшы, хуш. Китап чыгару белән дә, мәчет-мәдрәсәләр салдыру, уку-укытуны алып бару белән дә шаккатырып булмый инде безне. Халкыбыз 60 ел динсезлек чорын кичерде, берсен-берсе алыштырган 3 буын динсез үсте. Моннан 16 ел элек туган авылында шушы бушлыкны тутырырга тәвәккәлләп, гаиләсен, нәселен шушы изге ниятне гамәлгә ашырырга оештырган, халыкны да күтәрә алган замандашыбыз китабында моңа ничек ирешүе, тәрбия-аңлату ысуллары хакында гади генә итеп тәҗрибәсен уртаклаша.




70 йортлы Өркешендә һәр гаилә, һәр бала өчен кадерле зат, кирәкле шәхес ул бүгенге көндә. Авылдашларының ихласи язмалары аша без бирердә халыкның тирән тамырлы дини-милли мирастан өзелмичә, дини тәрбиянең, иң әвәл уку-укытуның милли тәрбия белән тыгыз үрелеп баруын күрәбез.

15 елдан артык Казанның «Гадел» мәчетендә уку-укыту буенча имам ярдәмчесе буларак, ел саен йөзләгән кешегә динне төшендерүне оештыруы, туган авылында гаиләсе, туганнары белән бергәләп «Фәниябикә» мәдрәсәсен төзеп, уку-укытуда күптармаклы тәрбия проектларына алынган Фәния ханым Җәләлиева үз мәктәбен, үз алымнарын булдырган олы йөрәкле тәрбияче, бай тәҗрибәсен һәркем белән уртаклашырга әзер мөгаллимә буларак ачыла китапта.

Автор хезмәтенең икенче өлешендә хикмәтле гыйлемнәр, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (салләллаһу галәйһи вәссәллам) заманыннан башлап безнең көннәргә кадәр тарикать әһелләре, хөрмәтле ишаннар, әүлиялар аша килеп ирешкән зикер-салаватлар хакында тәфсилләп яза. Тарикать юлын гади генә аңлату белән бергә, тәүге адымнарны ничек башларга кирәклеген адымлап-адымлап аңлата. («Күңелләр дәвасы» китабы белән танышканнан соң, Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев: «Әле моңарчы ир-ат затындагы замандашларыбыз арасында бер галимнең, дин әһеленең дә тарикать хакында һәркемгә аңлашылырлык гади дә, кыю да итеп язып чыкканы юк иде. Фәния ханым әлеге бушлыкны тутырырга башлап юл ярды», – дигән бәясен ирештерде).

Мөселман җәдвәле буенча һәр айда, дини бәйрәмнәребездә, изге көннәрдә нинди догалар укып Аллаһка якынаерга, фани дөньяда инсанны сынаган авырлыклар, авыру-сырхаулар вакытында югалып калмыйча, ничек итеп Раббыбыздан җиңеллек сорап ничек сыгынырга – китапта боларга җавап табарга була. Автор әлеге бер тәртипкә салып, туплап биргән зикерләрне әкренләп гамәл-гыйбадәткә кертү хакында да тәҗрибәсе белән уртаклаша, тәфсилләп аңлата.

Бу нәселдә дәвалау, халыкка игелек кылу кендек әбисе, халык табибы булып тирә-якта дан тоткан ерак әби-бабаларыннан ук килә. Ә Хөрмәтулла кызлары Фәния һәм Әлфия ханымнар, Фәния ханымның җәмәгате Рәшит Әгъзәм улы һәм кызлары Асия Рәшитовна белән Айгөл Тәбрисовна гомерләрен инсаннар дәвалауга багышлаган, табиблык итүне сайлаган игелекле һөнәр ияләре. Дин ирекле килгәч, халкыбызның тәнен генә түгел, күңелен дәваларга, савыктыруга алынучы фидакарьләр буларак Аллаһы Тәгалә юлында алар ихлас тырышлык куялар. Фәния ханым тирәсенә тупланган гаиләнең эшчәнлеген бер китапка җыюны һәм зур нәселнең күңел хәзинәсен киң катлау укучыларга җиткерүне мөхәррир Вәсилә ханым Рәхимова оештырган. Китапны Казанның «Гадел» мәчетендә һәм Тукай урамы, 5нче йорттагы «Рамазан» кибетендә сатып алырга мөмкин.

**ВӘСИЛӘ РӘХИМОВА**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ**

# Мөселманда хатын-кыз

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

Ислам дине килгәнче хатын-кызлар күпме кимсетелүләргә дучар булган!

Мәсәлән, ислам динен кабул иткәнче гарәпләр, ярлылык һәм хурлыктан куркып, яңа туган кыз балаларын тере килеш күмгәннәр. Коръәни-Кәримдә бу турыда болай диелә: «Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә «кыз балаң туган», дип, сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып, йөзе каралып китәдер. Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып кавеменнән качадыр, уйлап торадыр: бу кызны хурланып кына асраймы икән? Яки терелэтә туфракка күмеп таптыймы икән, дип. Әгаһ булсыннар, кылган эшләре нинди яман кабахәт эштер!» (16:58-59)

Ислам дине килү белән хатын-кызларда хокуклар барлыкка килә. Аңа хөрмәт белән карый башлыйлар. Ислам динендә ана хокуклары ата кеше хокукларыннан өстенрәк була башлый. Моны Әбү Һөрәйрә китергән хәдис дәлилли. «Бер кеше Пәйгамбәрдән (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) сорый: «Кешеләрдән кайсысы минем яхшырак мөгаләмәмә лаеграк?» Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) әйтте: «Синең әниең». Кеше сорады: «Ә аннары кем?». Кабат: «Синең әниең», –диде. Кеше сорады: «Ә аннары кем?» Пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) җавап бирде: «Синең этиең».

Ислам дине килү белән «хатын-кыз» сүзе горурлык белән әйтелә башлады, чөнки бу сүз белән Коръәни Кәримдәге зур сүрәләрнең берсе атала. Аллаһы Тәгалә дине хатын-кызларга мирас калдыру хокукы бирә һәм шулай ук хатын-кыз милкен кагылгысыз итә.

Ир-ат таш һәм кирпечтән йорт салса, бу йорт –әлеге дөньяның бәрәкәте, ә йортка тугрылыклы хатын-кыз тутырган ямь, җылылык һәм тәрбия әлеге һәм киләчәк дөнья өчен бәрәкәт булып тора.

Йорт – мөселман кешесенең ныгытмасы. Әгәр дә бу ныгытманы төзүдә хатын-кыз катнашмаса, анда бәрәкәт булмый. Аллаһы Тәгаләне зикер иткән, ислам динен өйрәнгән, тугрылыклы мөселманнар тәрбияләгән гаиләләр бәхетле.

Ана – батырларны, галимнәрне һәм тәкъва кешеләрне тәрбияләүче. Безне чын тормыш белән таныштыручылар – күркәм холыклы, дини, белүче, сабыр, дога кылучы, үкенүче әниләребез.

Мондый хатын-кызларның берсе белән Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) пәйгамбәр булганчы да, булгач та ризалыкта тигез тормыш кичергән.

Хәдичә – ислам динен беренчеләрдән кабул итүче, Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) белән беренче намаз кылучы, беренче Җәннәт белән шатландырылучы, Коръәнне беренче ишетүче.



Аны Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аша сәламли. Ул үзенең байлыгын Аллаһы Тәгалә юлына тота. Пәйгамбәребезне (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) кешеләр кире каккач та, ул аңа ышана, ялганда гаепләгәч – хаклыгын раслый, ярдәмсез калдыргач – ярдәм итә. Һәм Аллаһы Тәгалә аларны балалар белән шатландыра.

Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәссәлләм) Хәдичәдән туган кызы Фатыйма, Хәсән белән Хөсәеннең әнисе, Галинең хатыны – бөтен хатын-кыз һәм барлык аналар өчен үрнәк булып тора.

Гайсә пәйгамбәрнең әнисе Мәрьямнең диндарлыгы хакында Коръәни Кәримнең күп кенә аятьләрендә әйтелә. Аның исеме белән Коръәни Кәримнең сүрәсе атала. Фиргавен хатыны Асия дә, иренең ышанмавына карамастан, Аллаһы Тәгаләгә ышана. Ул Муса пәйгамбәрне тәрбияли.

Бөек галимнәр, укытучылар тормышын өйрәнсәк, аларның галим булуларында яшьтән үк белем алырга өндәгән әниләренең өлеше зур. Мисал итеп, Әбү Хәнифә, Имам Шәфигыйны һ.б. китерергә була.

Уйланыгыз! Хатын-кызларга аеруча ихтирам күрсәтелә башлау ислам дине белән бәйле түгелме соң? Ирләре хатыннарын саклап кына торырдай энҗе бөртеге дип атамыйлармы? Мондый хөрмәт Аллаһы Тәгаләгә буйсынган, Аның күрсәтмәләрен башкарган һәм тыйганнарыннан баш тарткан хатын-кызларга гына насыйп була.

Ир-атларның дүрт хатын-кызга карата бурычлары бар: әнисенә, хәләл җефетенә, сеңлесенә һәм кыз баласына. Аллаһы Тәгалә бездән аларның һәрберсе турында сораячак. Без аларның хокукларын саклаганбызмы? Әниебезнең сүзен тыңлаганбызмы, аңа карата яхшы теләктә булганбызмы, шатландырырга тырышканбызмы? Сеңлебезне яклаганбызмы, хәләл җефетебезгә карата гадел булганбызмы, кыз балабызга дөрес тәрбия биргәнбезме?

Әйе, кардәшләр, бу чынлыкта да шулай. Әгәр дә без, ир-атлар, хатын-кызларыбызның һәрберсенә тиешлесен бирсәк, гаилә бәйләнешләре нык булачак, ә моның белән бергә без яшәгән җәмгыять тә күпкә яхшырачак.

Язмамны тәмамлап, сезгә Аллаһы Тәгалә сүзен искәртәсе килә: «И кешеләр! Сезне бер ата-анадан яратучы Аллаһыга каршылык күрсәтүдән сакланыгыз, Ул Адәм галәйһиссәламнең үзеннән хатын яратты вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһыга тәкъвалык кылыгыз ки үзегез, Ул – Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, шулай булгач, Аллаһыны зурлагыз вә якын кардәшләр хакыннан сакланыгыз! Бит Аллаһ сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче» (Коръән. «Ниса»/«Хатыннар» сүрәсе, 1 аять).

**ГАБДУЛЛА ХӘЗРӘТ**


## ИМАН ҺӘМ ГАМӘЛЛӘР

**Имам Әбу Хәнифә (Аллаһ аннан разый булса иде) болай дигән: «Гамәл – иман түгел, ә иман гамәл түгел».**

Мин: «Бу фикер хакыйкать яклы булганнарныкы, аларга хариҗилар каршы чыга», – дип әйтәм.

Имам Ибне Хәҗәр әл-Хайтами имам ән-Нәвавиның «Кырык хәдис»енә аңлатмасында болай ди: «Иман телдә хакыйкатькә инануны аңлата, ә бу иманның шарты – бары тик калебең (күңелең) белән ышану», – алга таба дәвам итеп: «Кайберәүләр, иманның шартларына тел белән (шәһадәтне) әйтүне һәм гамәлләр кылуны да кертергә кирәк, кемнәрнең шушылардан кайсы да булса берәрсе булмаса, көферлеккә төшә, дип әйтә, һәм бу хариҗилар фикере».

Әлеге китапта файдалы әйберләр бик күп, ачып укып карагыз.



Имам болай ди: «.. дәлилләргә бәйле рәвештә, күп вакыт кешедә гамәлләр үтәү бурычы ятмый, әмма моның белән анда иман бурычы юк дип әйтергә ярамый.

Хәез вә нифас вакытында хатын-кызлардан намаз уку бурычы төшә, әмма аннан иман бурычы төшкән һәм иманны калдырып торырга кушылган дип әйтергә ярамый.

Бөек Раббыбыз аңа мондый чакта ураза тотмасын, соңыннан (ураза) көннәрен тутырып тотып бетерер дип әйткән, әмма аңа иманны калдырып торырга, аннары аны каза кылырга кушылды дип әйтергә ярамый».

Мин: «Хатын-кызлар, «Мифтах әс-Сәгадә»дә әйтелгәнчә, хәез вакытында ураза тотмый һәм аны пакьләнгәннән соң үти», – дип әйтәм. Һәм бу гамәлләрнең иман түгеллегенә күрсәтә.

Имам: «Фәкыйрьдә зәкят түләү бурычы юк, дип әйтергә мөмкин, әмма анда иман бурычы юк, дип әйтергә ярамый», – ди.

Аллаһы Тәгаләнең сүзләренә бәйле рәвештә, иман – гамәл булып, ә гамәл иман булып тормый:

Мәгънәсе: «Иман китергән бәндәләремә әйт: намазларын калдырмыйча, дөрес укысыннар...» («Ибраһим» сүрәсе, 31нче аять).

Һәм Аллаһы Тәгалә аларны намаз укыганга кадәр үк иманлылар дип атаган. Шул ук сүзләр «Бәхер әл-Каләм»дә дә әйтелгән.

**РӘШИД ИСАЕВ**

# Мәдрәсәләребез – «татар академияләре»

Яңарыш хәрәкәтенең бер чагылышы булган әлеге күренешнең 1920-1930 елларда да уңышлы дәвам иттерелүе татар филологиясе фәненә үзләреннән ифрат зур өлеш керткән күренекле галимнәр Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Г.Баттал, Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәти, Г.Ходаяров, С.Атнагулов, В.Хангильдин, Г.Алпаров, Н.Хәким, Г.Нугайбәк, Г.Шәрәф, Х.Бәдигый һ.б. исеме белән тыгыз бәйле булып, аларны бүген зур горурлык белән телгә алабыз. Әлеге шәхесләрнең һәммәсе диярлек 1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәр татар мәдрәсәләрендә белем-тәрбия алган һәм әлеге гамәл аларга яңа шартларда, совет чорында дөньяви милли мәдәниятне, фәнне, мәгарифне үстерү эшендә ярдәм иткән. Татар мәдрәсәләрендә бирелгән динирухи тәрбия һәм дөньяви белемнәрнең фәнни-мәдәни потенциалны тудыруда ничек катнашуы, әлеге галимнәребез хезмәтләрендә, эшчәнлекләрендә, иҗат мирасларында ни рәвешле урын алуы мәсьәләсе әле җитди тикшеренүләрне көтә. Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән әлеге мәкаләдә без 1920-30 еллар татар филологиясе фәне үсешендә тирән эз калдырган күренекле галимнәр Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Җамал Вәлидиләрнең галим булып формалашуы һәм үсешендә алар укыган атаклы «Галия» һәм «Иж-Буби» мәдрәсәләренең ролен билгеләүне максат итеп куябыз.

Әлеге мәсьәләне исемнәре югарыда аталган өч филолог-галим шәхесе мисалында алып тикшерүебез очраклы түгел. Аларның тормыш һәм иҗат биографияләрендә, язмышларында үзара кисешкән уртак нокталар бар.

Инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә белем алып, Октябрьдән соңгы каршылыклы чорда фәннимәдәни һәм иҗтимагый мәйданда актив эшчәнлек алып барганнар, милли фәнне үстерүгә күп көч салып, татар филологиясе өлкәсендә зур галимнәр булып танылганнар. Ни кызганыч, татар фәнен үстерүгә зур хезмәт куйган әлеге фидакарь затларыбызның өчесе дә шәхес культы корбаны – 1930 елларның канлы «тегермәнендә» тарттырылган, нахакка рәнҗетелеп, юк ителгән фаҗигале шәхесләр.

Г.Ибраһимов белән Г.Нигъмәтинең әдәби һәм фәнни биеклекләргә күтәрелүенең юл башы «Галия» мәдрәсәсенә барып тоташа, ә Җ.Вәлиди «Иж-Буби» мәдрәсәсендә белем ала. Г.Ибраһимов «Галия»дә 1906-1909 елларда укый, ә 1915-1917 елларда әлеге мәдрәсәдә укытучы булып эшли; Г.Нигъмәти исә әлеге мәдрәсәдә 1911-1917 елларда укый. Җ.Вәлидинең «Иж-Буби» мәдрәсәсендә укуы 1904-1911елларга туры килә.

XIX гасыр азагы – XX гасыр башларында Ижау ягындагы «Иж-Буби», Уфадагы «Галия», Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре статуслары белән чагыштырмача бердәй дәрәҗәдә торган, дини белем бирү белән бергә гимназия курсы буенча дөньяви фәннәр укытуны да күздә тотып эшләгән җәдиди юнәлештәге яңа тип татар уку йортлары булганнар. Р.Әмирханов «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен чын мәгънәсендә Октябрьгә кадәрге чорның татар университеты дип атарга мөмкин дисә; А.Мәхмүтова «Буби» мәдрәсәсен шул чор рус-татар зыялылары даирәсендә «мөселманнар академиясе» дип йөрткәннәр дип яза, «Галия» мәдрәсәсен «халык университеты» тибындагы уку йорты дип бәяләүләр дә була.

Г.Ибраһимов иҗатын өйрәнгән М.Хәсәнов «Галия» мәдрәсәсе турында «милли институт дәрәҗәсендәге мәшһүр уку йортларының берсе булган» дип яза.

Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Җ.Вәлидиләр укыган чордагы мәдрәсә программаларына күз салсак, анда дини һәм дөньяви фәннәрнең бердәй тигез дәрәҗәдә булуын күрәбез.

ДӘВАМЫ 5 НЧЕ БИТТӘ

# Мәдрәсәләребез – «татар академияләре»

*Дәвамы. Башы 4 нче биттә*

Шәкертләргә төрле яклап системалы белем бирелгән. Гуманитар юнәлешкә караган предметлар саны гына да ике дистәдән артып китә. Мәдрәсәләрдә дини белем бирүдә мәгърифәтчел принциплар күздә тотылуын ассызыклап әйтергә кирәк. Үз вакытында Г.Утыз-Имәни «Мәгърифәтле булу – гыйлемле булу, гыйлемле булу – Коръәнне белү» дип аңлаткан. Шәкертләрдә дини дәресләрне укыту аша рухи бөтенлек тәрбияләнгән.

Мәдрәсәдә укыган чорда Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Җ.Вәлидиләргә дини белемнәр системасы аша рухи-әхлакый тәрбия бирелгән. Бу урында шуны да билгеләп үтик, 1920-1930 елларда актив эшчәнлек алып барган Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәтиләрнең һәм шәхес, һәм галим буларак югары әхлак сыйфатларына ия булулары турында язалар икән, бу аларның табигый асылыннан тыш, мәдрәсәләрдә укып, дини тәрбия алулары, дин әхлагы нигезләрен үзләштерүләре белән бәйле булган. Мисал өчен, әдәбият тәнкыйтьчесе Г.Нигъмәтинең 1920-30 елларның катлаулы шартларында язучы-тәнкыйтьчеләрне төркемнәргә аермыйча, һәммәсенә хөрмәт белән каравын, әдәби судларда катнашып каләмдәшләрен кимсетмәвен, намуслы, кешелекле булып калуын искәртеп китәргә мөмкин.

«Галия» мәдрәсәсе укытучы кадрлар составының югары әзерлекле булуы белән аерылып торган. Бу мәдрәсәне нигезләүче Зыя Камали (Камалетдинов Пәрвазетдин Җамалетдин улы) үзе Каһирәдәге «Әль-Әзһәр» дини академиясен тәмамлаган зур гыйлем иясе, алдынгы карашлы кеше була. Мәдрәсәдә дин тәгълиматын, ислам фәлсәфәсен, этика фәннәрен укыта. Үз тирәсенә белемле, югары әзерлекле кадрларны туплый. «Галия» мәдрәсәсендә Багдад, Каһирә, Казан, Мәскәү университетларын, Төркия югары уку йортларын, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган белгечләр укыткан. Г.Ибраһимов (татар теле һәм әдәбияты), Ә.Вәлиди (фәлсәфә), Г.Терегулов (психология), З.Кадыйри (гарәп, төрек телләре), Ф.Сәйфи-Казанлы (тарих), Г.Шинаси (педагогика, методика), Г.Фәезханов (математика), В.Клеменц (Варшава консерваториясе профессоры; музыка укытучысы) кебек күренекле шәхесләр белем биргән биредә. Алар укучыларында фикер һәм акыл сәләте, өйрәнелә торган фәннәргә карата иҗади мөнәсәбәт тәрбияләүгә һәм үстерүгә җитди игътибар биргәннәр. Иң элек мәдрәсә җитәкчесе, дин мөгаллиме Зыя Камали үзе укучыларында фикерләү сәләте уятырга тырышкан, лекцияләрен актуаль фәнни темаларга укыган. Хезмәтләре аша да («Ислам фәлсәфәсе» һ.б.) мөселманнарны фикерләү юлына этәрү максатын куйган. Чын исеме Пәрвазетдин булып, Зыя (зыя–гарәп сүзе: яктылык, нур, белем, мәгърифәт дигән мәгънәне аңлата) тәхәллүсен сайлау фактын да бу кешенең үзен фәнгә, белемгә багышлавы турында ачык сөйли булса кирәк. Мәдрәсәдә шәкертләрнең фикри үсешенә этәргеч бирә торган мантыйк, мөназара (бәхәс) фәннәре укытылу факты турында да әйтеп китәргә кирәк. Шәкертләрне бәхәсле хәл тудыру һәм аны алып бару методикасына өйрәткәннәр. Бу исә булачак галим кеше өчен бик мөһим сыйфатларны тәрбияләүгә ярдәм иткән. 1920 елларда иҗат иткән татар галимнәренә фикер үткенлеге, фәнни хакыйкатькә ирешүдә бәхәс алымын кулланып эш итү сыйфатлары хас булган икән, моның очы әнә шул мәдрәсәләрдә алган белем һәм күнекмәләргә барып тоташа.

Тирән белемле Зыя Камалинең Г.Ибраһимовка тәэсире зур булган. 1915 елда «Галия» мәдрәсәсе турындагы бер мәкаләсендә танылган әдип болай дип яза: «Миңа иң беренче тәэсир итүче Шиһаб хәзрәт булса, икенчесе Зыя Камалидыр. Бу ике затка мин гакылымны азат кылу, фикеремә истикълал (бәйсезлек, иркенлек) бирү юлында мәңге бурычлымын. Болар минем фикри тәкаммелемнең (камилләшүемнең) үткән бер баскычында иң кирәкле мөәссир (тәэсир итүче) булдылар. Бер мин генә түгел, үзләренең үткәннәреннән хисап бирүче күп татар яшьләре дә моны икърар (тану) кыйлачаклар».

«Галия»дә укыганда ук Г.Ибраһимов фәнни иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. 1909 елда «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән һәм шул ук чорда «Европа философы Декарт һәм аның нәсыйхәте» кебек беренче фәнни хезмәтләрен бастырып чыгара. Соңрак, мәдрәсәдә укыта башлагач, шәкертләр һәм мөгаллимнәр алдында тел-әдәбият мәсьәләләре буенча лекцияләр укый. Тел-әдәбият фәннәрен укыту тәҗрибәсенә таянып, методик характердагы хезмәтләрен яза. (1920 елларда аерым мәкаләләр яисә фәнни хезмәтләр рәвешендә бастырып та чыгара). Аларның эчтәлегендә галимнең тел һәм әдәбият мәсьәләләрен аңлатудагы фәнни концепциясе оешу эзлекле чагылыш таба. Аерым алганда, Г.Ибраһимов теге яки бу халыкның теле, әдәбияты үсеше аның тарихи үсеше, шул халыкның тормыш дәрәҗәсе, җитештерү һәм рухи эшчәнлеге ихтыяҗлары белән билгеләнүен яхшы аңлаган.

1920-30 елларда Г.Ибраһимов җитәкчелегендә татар галимнәре тел-әдәбият күренешләрен билгеле бер халык мәдәниятенең органик өлеше итеп карап, аларның үсешен, яшәешен теге яки бу халыкның милли үзенчәлекләре, иҗтимагый-сәяси яшәү шартлары белән бәйләнештә өйрәнәләр. Шунысы игътибарга лаек, программаларда каралган фәннәрне укыту өчен мәдрәсә китапханәләрендә кирәкле әдәбият, уку әсбаплары тупланган була. Мәсәлән, «Галия» мәдрәсәсенең бай китапханәсендә дини, дөньяви әдәбият, татар, рус, гарәп, фарсы телләрендәге газета-журналлар, ислам нигезләре, гомуми тарих, психология, мантыйк һ.б. фәннәр буенча уку әсбаплары, Пушкин, Гоголь, Чехов, Горький кебек рус,



Тукай, Рәмиев, Әмирхан, Гафури, Исхакый кебек татар әдәбияты вәкилләренең әсәрләре урын алган. Әлеге факторлар «Галия» мәдрәсәсе шәкертләренең (шул исәптән, Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәтиләрнең дә) дөньяга карашын үстерүгә көчле тәэсир ясаган, аларның фәнни мәнфәгатьләре формалашуга этәргеч биргән.

«Галия» мәдрәсәсендә укытканда Г.Ибраһимов әдәбият программасына дөнья классикасының иң әйбәт үрнәкләрен тәрҗемә итеп кертүне көн тәртибенә чыгара. Һәм, әйтергә кирәк, алга таба фәнни иҗат практикасында, киңкырлы эшчәнлегендә үзе дә Көнчыгыш, рус, Европа әдипләренең, фикер ияләренең әсәрләренә, хезмәтләренә киң таяна. «Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм офыгына таба юнәлдерергә – бәни адәм хәятенең борынгы заманнардан алып әдәбиятта ничек ингыйкас итә барганлыгы белән танышырга, кыскача әйткәндә, татар әдәбиятыннан үтеп, бөтендөнья әдәбиятының тарихи агымнары белән дә танышырга лазем булачак. Киләчәк көнебезнең яктыруы өчен Гареб мәдәнияте белән файдалануыбыз никадәрле лазем булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрыкның үткәне белән дә азыкланырга тиештер», – дип яза ул 1915 елда бер мәкаләсендә. Г.Ибраһимовның әлеге фикерләрен укучысы, фикердәше Г.Нигъмәти дә уртаклаша.

«Буби» мәдрәсәсенең уку-укыту программаларыннан чыгып сүз йөрткәндә, бу уку йортында да киң һәм төпле гуманитар белем бирелгән: фәлсәфә, мантыйк, метафизика, этика, Россия һәм Шәрык тарихы, гомуми тарих, ислам тарихы, риторика, шигырь төзелеше (гаруз), этика, рус, төрек, фарсы, гарәп, немец һәм француз телләре, рус, татар әдәбияты кебек фәннәр укытылган; дини тәгълиматны өйрәнүгә дә киң урын бирелгән. Җ.Вәлидинең укытучысы, «Буби» мәдрәсәсе мөгаллиме Габдулла Буби шәкертләрен Коръәннең камил мәгънәсенә төшенү өчен мөстәкыйль фикерләргә, уйларга, хакыйкатьне эзләү юлына өндәгән. Мәдрәсәдә иҗади-эзләнү эшенә зур игътибар бирелгән. Мәсәлән, шәкертләр катнашындагы кичәләрдә төрле темаларга докладлар, рефератлар укылган, газета материаллары буенча чыгышлар, аерым мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган сөйләшү-бәхәсләр оештырылган. Болар шәкертләрнең танып-белүгә кызыксынуын үстергән. Биредә укыган Җ.Вәлидинең киләчәктә мәдәниятне яхшы белүче фән эшлеклесе, галим булып формалашуында әлеге чараларның роле зур булган.

«Буби», «Галия», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләренең уку-укыту программалары белән рус гимназиясе, реальный училище, Казан татар укытучылар мәктәбе программалары арасында уртаклык күп. Шуңа күрә Җ.Вәлидигә туганы С.Җәлал белән бергә «Буби»дан соң Казан Татар укытучылар мәктәбенә кереп уку артык кыенлыклар тудырмаган. «Буби» мәдрәсәсендә алган белемнәре Җ.Вәлидигә «Вакыт» газетасында, «Шура», «Аң» журналларында иҗтимагый һәм эстетик фикер үсешенә җитди өлеш кертерлек күпсанлы мәкаләләр белән чыгыш ясау югарылыгына күтәрелергә юл ача. Алган белеме чорның билгеле уку йортларыннан саналган «Хөсәения» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты буенча мөгаллимлек итәргә мөмкинлек бирә.

Боларга өстәп шундый факт турында әйтеп китәргә мөмкин: Г.Нигъмәти «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1920 елларда укуын Мәскәүдә Дәүләт журналистика институтында дәвам итә, аннары Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик университетында (КУТВ) укый. Бу уку йортларында ул танылган шәркыят белгечләре, совет галимнәре лекцияләрен тыңлый. Гомумән, «Галия» мәдрәсәсе Г.Нигъмәтидә яңа заман рус-Европа гыйлеме казанышларын кабул итү өчен уңышлы җирлек әзерләү белән бергә, дәүләт, хөкүмәт, җәмәгать һәм фән, мәдәният, мәгариф оешмаларында, төрле җаваплы урыннарда эшчәнлеген уңышлы алып барырга тулы мөмкинлек бирә. Ә инде «Мөхәммәдия», «Галия» мәдрәсәләрендә рус теле, тарих, Коръән нигезләре, Шәрык фәлсәфәсе кебек предметлар буенча алган белем Г.Гобәйдуллин, Г.Нигъмәти, Г.Толымбайларга Мәскәүдәге Кызыл профессура институтында укыганда (1920-1940 елларда вузлар өчен укытучылар, фәнни-тикшеренү учреждениеләре, партия, дәүләт органнары өчен фәнни хезмәткәрләр әзерләүче махсус уку йорты) әлеге вуз программасына кертелгән гуманитар фәннәр буенча курсларны уңышлы үзләштерергә ярдәм иткән дип фаразлый алабыз.

1926 елда Казанда Көнчыгыш педагогия институтында татар теле һәм мәдәнияте бүлеге оешкач, шунда татар теле, чагыштырма төрки-татар тел белеме, татар халык авыз иҗаты, татар халкы тарихы, татар әдәбияты, шәрык әдәбияты, методика курсларын укытканда Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Г.Нигъмәти, Җ.Вәлидиләр инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә һәм соңрак совет югары уку йортларында алган тирән белемгә таянып эшлиләр. Шул рәвешле, алар үзләренең киңкырлы белемнәрен милли кадрлар әзерләү эшенә багышлыйлар.

XIX гасыр ахырында мәдрәсәләрдә татар теле укытыла башлау Җ.Вәлиди, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимовларда татар-төрки тел гыйлеме белән кызыксынуны кузгаткан һәм алар алга таба фәнни эшчәнлекләрендә шул юнәлешне дә үстереп, тирәнәйтеп, алга таба тел галимнәре булып та таныла лар. Мәсәлән, Җ.Вәлиди 1920 елларда Көнчыгыш педагогика институтының татар бүлегендә татар телен укыткан, тел гыйлеме буенча дистәләрчә фәнни хезмәтләр язып чыгарган һәм аларның күбесе студентлар өчен дәреслекләр сыйфатында кулланылган.

Ә инде татар әдәбияты дәресләрендә «Уку китабы» сыйфатында борынгы дини-әхлакый эчтәлекле хезмәтләрдән, татар фольклоры үрнәкләреннән, шәрык, XIX гасыр һәм XX гасыр башы татар әдипләренең әсәрләреннән туплап төзелгән хрестоматияләр файдаланылган. «Галия»дә татар әдәбиятыннан алган белеме Г.Нигъмәтигә 1920 еллар башында аны КХКУда, алга таба Көнчыгыш педагогия институтында югары дәрәҗәдә укыту мөмкинлеге биргән. Тел-әдәбият профессор-доцентлары Г.Сәгъди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Җ.Вәлидиләр хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Мәдрәсәдә укыганда өйрәнгән борынгы авторларның дини-әхлакый эчтәлекле «Кыйссаи-Йосыф», «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә», «Фәзаил-әшшөһүр», «Мөхәммәдия», «Бакырган», «Кисекбаш», «Кыйссасел-әнбия», «Алты бармак» һәм аннан соңгы чорларга караган татар авторларының әсәрләре, мәдрәсәләрдә әдәбият теориясе нигезләре буенча алган белемнәре әлеге галимнәргә татар әдәбияты, иҗтимагый һәм эстетик фикер тарихы буенча хезмәтләр язганда ышанычлы таяныч булып торган. Гарәп, фарсы, төрек, рус, немец, француз телләрен белү булачак татар филолог-галимнәренә Шәрык, рус-Европа чыганаклары белән турыдан-туры танышу мөмкинлеге биргән. Инде килеп, татар мәдрәсәләрендә киң планда тарих фәне укытылуны һәм алга таба бу фәннәрне Г.Газиз, Г.Рәхимнәрнең дөньяви югары уку йортларында тагын да киңәйтеп, тирәнәйтеп өйрәнүен, әлеге белемнәрен татар тарихы, тел, әдәбият тарихы буенча фәнни хезмәтләрен язганда куллануларын ассызыклап күрсәтү сорала.

Әдәбият галиме Г.Нигъмәти үз хезмәтләрендә эстетиканың, әдәбият теориясенең фәлсәфи нигезләрен аңлатканда, моңа хәтле мәдрәсәдә ислам тәгълиматын өйрәнү аша алган фәлсәфи гыйлемнәрен башка фәлсәфи системалар белән кушып файдалана. Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәтиләр мәдрәсәләрдә психология буенча алган белемнәрен алга таба тагы да киңәйтеп, тирәнәйтеп, 1920 елларга караган фәнни хезмәтләрендә иҗат психологиясе, язучы һәм укучы психологиясе мәсьәләләренең фәнни яктыртылышын тикшергәндә файдаланалар.

Шул рәвешле, дини мәдрәсәләрдә һәм югары уку йортларында белем алу Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим кебек шәхесләргә мөселман һәм яңа заман мәдәниятен үзара бәйләү, Шәрык һәм рус-Европа әдәби-эстетик фикерен синтезлаштыру мөмкинлеге бирә. Нәтиҗәдә алар татар гуманитар фәне үсешенә зур өлеш кертерлек галимнәр булып тарих мәйданына чыгалар.

**ЭЛЬМИРА ГАЛИЕВА**

**«ТАТАР – ИСЛАМ»**

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

# Шәех Зәйнулла Рәсули

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

1869 елның 18 сентябрендә Истанбулга килеп төшкәч тә, ул мәшһүр төрек шәехе Әхмәт Зыяэтдин бине Мостафа Кәмешханәви белән очраша, элеккеге шәехенә мөрид булудан баш тартып, төрек шәехенә «кул бирә» – мөрид була. Яңа шәехенең җир астында ясалган «хилвәтханә»сендә – япа-ялгыз, тынга калып, гыйбадәткә, тирән уйга һәм транска (гадәти психик халәттән чыгуга) талып утыру өчен ясалган аулак бүлмәсендә 40 тәүлек утыра. Тәүлекнең билгеләнгән вакытларында, шәехе белән генә очрашып, аңардан өйрәтмәләр, күрсәтмәләр, киңәшләр (тәрбия) ала. Аннан, Мисыр аша, Мәдинә шәһәренә юл тота. Рамазан аен Мәдинәдә үткәрә. Анда да чорының күренекле суфи шәехләре белән очраша, алардан да ишанлык сабаклары ала. Хаҗ фарызларын үтәгәннән соң, кайтышлый тагын бер айга Истанбулда туктала. Шәехе белән очраша. Тарикать сабакларын үзләштереп, шәехеннән ишанлык иҗазәтнамәсе-шәһадәтнамәсе алып кайта. Гадәти ишанлык ысулын тарсынган, ниндидер яңа юл эзләгән кеше бер Зәйнулла хәзрәт кенә булмаган, күрәсең: ишан булып кайту хәбәре таралу белән, тирә-як халыклары ташкын булып аңа «кул бирергә» – мөридлеккә агылалар. Бу кадимче муллаларны, ишаннарны аңа каршы аякландыра. Өметле мөриденең үзеннән читләшүе элеккеге шәехе Габделхәким ишанны үртәндерә. Башка мөридләренең үзеннән аерылып, яшь Зәйнулла ишанга күчүләре инде аны чыгырыннан чыгара. Мөридләрен кабул итмәвен – үз ягына тартмавын таләп итеп Зәйнуллага язган кисәтү хатлары да нәтиҗә бирми. Тиздән яшь шәех дошманнары төркемендә Эстәрлебаш ишаны Кәмалетдин, Оренбург ахуны Хисаметдин кебек чорының иң мәшһүр руханилары да кушыла. Зәйнулла хәзрәт Төркиядән Нәкышбәнди тарикатенең Халидия тармагы гадәтләрен алып кайта. Алар зикерне аваз белән (джәхри) һәм ритмик хәрәкәтләр ясап әйтәләр икән. Зәйнулла хәзрәтне кеферлектә – динне бозуда гаеплиләр. «Биеп, әйләнгәләп һуштан язып егылып яталар да, тәһарәт яңартмастан, торып намазга басалар – шәригать кагыйдәләрен бозалар», – дип, Уфага Дини идарәгә һәм мөфтигә әләкләр юллыйлар. Халыкларны болгатуда, ниндидер хәрәкәт оештыруларда гаепләп, полиция идарәсенә һәм губернаторга донослар яудыра башлыйлар. Болары да, үзләре оештырган диярсең, әләкләргә җитди игътибар бирәләр. Мөфти, Зәйнулла хәзрәт дошманнарыннан, өч кешедән торган махсус комиссия төзеп, 1872 елның азагында яшь ишанны Дини идарә комиссиясенә тикшерүгә чакырта. Дини идарә, күрәсең, аны «тәүбәгә утырта»: нәрсәләрдер эшләмәскә кул куйдырып, өенә кайтарып җибәрә. Әмма ул инде бу сәфәреннән өенә әйләнеп кайта алмый. Аны туган якларында, күп санлы мөридләре арасында кулга алуның халыкны кузгатуы, болгатуы мөмкин дип курыкканнар, күрәсең, губернатор боерыгы буенча, юлда, иленнән еракта, Златоуст шәһәрендә кулга алалар.

Сигез айлап шул шәһәр төрмәсендә тотып, мәсьәләне җентекләп тикшергән төс күрсәткәннән соң, Вологда губернасына, Никольский дигән өяз шәһәренә сөргенгә озаталар. Мөридләреннән башка әле күпләргә билгесез яшь ишанны патша сөргене, татар дөньясында иң мәшһүр кешегә әйләндерә. Аның Кичүчат якларыннан үтүе турында Риза хәзрәт Фәхретдиновның истәлеге бар. Хаксызга рәнҗетелгән изге хәзрәт догасын алып калыр өчен ул узачак авылга тирә-як авыллардан күп халык җыела. Сыйларын әзерләп, тантаналы каршы алалар. Никольскийга урнашкач Кострома шәһәренең татар бистәсенә күчерү мәсьәләсен кузгаталар һәм максатларына ирешәләр. 1876 елда хәзрәт Костромага күчерелә. Гаиләсен дә Костромага үз янына китерүне оештыралар... Ниһаять, аңа авылына кайтырга рөхсәт итәләр. 1881 елның 1 ноябрендә ул Акхуҗага кайтып төшә.

Сигез ай төрмә, сигез ел сөрген... Нинди җинаять өчен? Белмибез. Муллалар, ишаннар белән кайбер ызгышлары гына билгеле. Түбәндә аның Никольскийдан язган хатын укучыларга тәкъдим итәбез. Хаттан да шул ызгышларны хөкем өчен сылтау иткәннәре аңлашыла. Әмма патша сәясәте татарлар, мөселманнар арасында ызгышлар – үзара чәйнәшүләр өчен һичкемне хөкемгә тартмаган. Андый чуалуларны, астыртын гына үстерергә, тирәнәйтергә, көчәйтергә генә тырышканнар. Барлык фетнәләр Төркиядән шәех булып кайткач башлана. Төрек шпионы дип гаепләрлек сылтау тапканнар, күрәсең, диярдең... Хөкемдә ул хакта бер кәлимә сүз булса, сөргенлек капкасыннан чыгуы белән, кеше андый гаепләүләргә кабат сылтау бирмәскә тырышыр иде. Ә ул?.. Олы бәладән котылу шөкранәсы өчен дип, 1882 елның җәендә үк кабат хаҗга китә. Һәм, юлда тагын ачыктан-ачык, шул элеккеге кыланышларын кабатлый. Бару һәм кайту юлында берәр айга Истанбулда туктала. Шәехе белән очраша. Юк, бу юнәлештә ул бернинди саклану, тыелу әсәре сиздерми.

Патша режимы, империя сәясәте каршында аның гаебе нидән гыйбарәт икәнен чорының башка бер күренеше – вәисиләр сектасы хәрәкәте белән чагыштыру аша аңлап була. Бөек борылыш-капитализмга күчү чоры бара. Ил тормышы җимерелүләргә, тетрәнүләргә йөз тоткан. Җәмгыять, кеше бу катаклизмнар якынлашуын, өстенә ябырылуын эчтән сизенә. Кеше бу борылышка – ниндидер шомлы эчке борчылуларга яраклаша алмый интегә. Моңарчы күрелмәгән рухи авырулар барлыкка килә. Кайбер ишаннар элеккеге «халык табиблары» кебек бу яңалыкларны аңламыйлар, юату чараларын, сүзләрен таба алмыйлар. Зәйнулла хәзрәт кебек, яңа этап руханилары булырга омтылган затлар яңа борчулар имчесе булу чарасын эзләп, «сектантлык» юлына басалар. Нәкъ шул елларда татар дөньясының үзәгендә, Казан шәһәренең үзендә хәтта, шундыйрак секталар – вәисиләр һәм «Баһави ишан» хәрәкәтләре куәт алалар. Аларны да шул шомлы тетрәнүләр мәйданга чыгара. Зәйнулла ишан хәрәкәтеннән аермалы буларак, бу секталарда элеккеге ишанлык чите-чоты («ишан», «мөрид» кебек атамалар) гына сакланып кала. Вәисиләр, «ерткычларга әйләнгәннәр» дип, барлык муллаларны, «имансыз» татарларны, мөфтине, барлык чиновникларны катгый инкарь итәләр, аларны җир йөзеннән бөтенләйгә себерәп түгәрдәй булып шаулыйлар.

Самодержавиенең төп терәкләре белән якага-яка килгән вәисиләр хәрәкәтен царизм 1884 елда гына тар-мар итә. Ә Зәйнулла ишан хәрәкәтен, әллә кайда читтә дип тормыйлар, оеша башлаган көннәрендә, тавышы чыккалаганчы ук 1873 елда ук җимерәләр. Юк, бу башбаштаклык, ялгышу нәтиҗәсе генә түгел. Моның җитди сәбәпләре бар. Беренчедән, Зәйнулла ишан хәрәкәте XVII-XVIII йөзләрдәге милли-азатлык кузгалышлары, сугыш мәйданнары булган Казахстан чиге, Урал буйларында башлана. Һәртөрле шикле адымнарны царизм биредә аерым күзәтү астында тота. Икенчедән, Зәйнулла ишан беренче адымнарыннан ук шаулау, чаң сугу ягына түгел, ә хәрәкәткә массакүләм төс бирү юлына йөз тота. Вәисиләр хәрәкәтендә исә ызгыш-шаулашулар өстенлек ала бара. Тиешле, тотрыклы нигезгә куелмаган шаулары белән алар үзләре үк киң катлау халыкны өркетәләр, үзләреннән читләштерәләр. Хәтта үзләренә каршы куюга да ирешәләр. Хәрәкәт шәһәрдәге, полиция күз алдындагы бер йорт эченә бикләнгән, йомык,




тамырсыз бер оешмага әйләнү юлыннан бара. Тынычлык шартларында, мондый нәрсә айнык сәясәтчеләрне әллә ни борчый алмый... Һәм тагын да җитдирәк өченче сәбәп: Зәйнулла ишан хәрәкәтендә царизмның котын ала торган, кардәш татар, башкорт, казах халыкларын бер оешмага, рухани башлык җитәкчелегендәге бер хәрәкәткә берләштерү мөмкинлеге башкарыла. Ызгыштыру принцибына нигезләнгән царизм сәясәтенә хәрәкәтнең нәкъ шул үзенчәлеге барыннан да хәвефле булып күренгәндер.

Нәкъ шул үзенчәлек «секта»ны сәяси хәрәкәт дәрәҗәсенә якынайта. Ниндидер сәяси автономия төсмере, мөстәкыйльлекләр мөмкинлеге күбрәк яшәгән казах халкы тирәсендә чаманы үтебрәк активлык күрсәтә башлавы хәрәкәтне туздыруга сылтау була.

Царизм эзәрлекләүләре, өркетүләре, дәһшәтле сөргеннәре Зәйнулла хәзрәтнең ихтыяр көчен какшата алмый. Киресенчә, аның татар, башкорт, казахлар арасында даны гөрләгән ишанлык дәвере, асылда, сөргеннән кайтканнан соң башлана. Бу эштә халыкның, җәмгатьчелекнең өлешен дә истән чыгарырга ярамый. Эзәрлекләнүче ишанны халык үз яклавы астына ала, аңа ярдәмләшә – уңайлыклар тудыра. Сөргеннән кайтуы белән, аны хаҗга барырга акча белен тәэмин итәләр. Хаждан кайткач, Троицкий шәһәренә имамлыкка чакыралар. 1884 елның 23 апрелендә Зәйнулла хәзрәт Акхуҗадан Троицкийга күчеп килә.

Кем белә, Акхуҗада гына яшәп калса, бәлки ул сөргенгә кадәргегә охшаш ызгышлар баткагына чумып, безгә мәгълүм мәшһүр Зәйнулла ишан була алмас иде. Шәһәрдәге мөмкинлекләр, үзенең тапкырлыгы һәм эшчәнлегенең колачлылыгы бик тиз аны теге ызгышлар һәм зәһәрле әләкчеләр буе җитмәслек дәрәҗәгә күтәрә. Дөрес, шәһәргә күченү белән, аның эшчәнлегенең мәгънәви юнәлешендә – эчтәлегендә дә җитди үзгәрешләр күзәтелә. Күрәсең, инде ул зикер җыелышларында төп игътибарын мәгариф өлкәсенә юнәлдерә. Троицкийга күчеп килгән елында ук, киң җәмәгатьчелек ярдәмендә тиешле матери-ал базасын оештырып, мәчете каршында зур мәдрәсә ачып җибәрә. Аның фамилиясенә нисбәт ителеп «Мәдрәсәи Рәсүлия» дип йөртелгән бу уку йорты Идел-Урал төбәгендәге мәгариф учакларының иң мәшһүрләреннән берсе булып кала. Идел-Урал буе халыкларына хезмәт күрсәтүдә Зәйнулла хәзрәт алгы планга – беренче урынга инде үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлеген куя һәм, зур казанышлары белән, бу төбәкнең иң күренекле мәгърифәтчеләре югарылыгына күтәрелә. Казах халкы тормышында да бу чорда, уяну, милли җанлану көннәре житлегеп килә. Шул җирлектә, Зәйнулла хәзрәтнең казахлар белән бәйләнеше аеруча якыная бара. Казахлар аның йөзендә бу чорда үзләренә ышанычлы рухи юлбашчы табалар. Хәзрәт даирәсе казах халкын агартуга да саллы өлеш кертә. Җәй көннәрендә, бераз акча табарга дип, хәзрәт шәкертләре «Рәсүлия»дән казах авылларына «мулда әкә»леккә – балалар укытырга агылалар. Мәдрәсәсен тәмамлаган байтак кына шәкертләрен дә ул, үгетләп, казах халкын агарту эшенә күндерә. Казах халкының үз эченнән чыккан шәкертләр дә «Рәсүлия»дә елдан-ел ишәя бара. Алар да, мәдрәсә тәмамлап, үз халыкларын агарту эшенә алыналар. Зәйнулла ишан казах халкына Гани бай Хөсәенов, Баруди хәзрәтләре татарларга күрсәткән хезмәтләрне күрсәтә.

Әмма болары әле аның казах халкы белән бәйләнешләренең өске катламын гына тәшкил итә. Казахстан халыкларының бала-чагалары, укучы яшьләре – шәкертләре генә түгел, өлкәннәренең дә бөтен катлаулары, бигрәк тә түбән катлау – гавам халкы хәзрәт белән тыгыз бәйләнештә була. Киң җәмәгатьчелек арасында ул, ишан буларак – рухи имче буларак таныла. Аның даны Тянь-Шань, Алтай итәкләренә кадәр тарала. Дәртләренә дәрман таба алмаган кешеләр, һәркайсы үз зары белән, Троицкийга ишан кабулханәсенә агылалар. Танышы-белеше юкларның төнләп урамда каласы юк. Хәзрәт шундый ерактан килүчеләр өчен ятакханә ясаткан. Анда көн-төн чәй кайнап тора.

Мохтаҗларны тукландыралар да. Билгеләнгән вакытта зарлылар алдында хәзрәт чыга.

ДӘВАМЫ 7 НЧЕ БИТТӘ

# Шәех Зәйнулла Рәсули

*Дәвамы. Башы 6 нче биттә*

Дога укый, вәгазь-нәсыйхәтләр сөйли, аларның зарын тыңлый. Шуңа мохтаҗ булганнары белән аерым очрашып та сөйләшә.

Яхшы психолог булган, күрәсең: кемгә юл күрсәтә, кемгә күңелен тынычландыра, кемгә киңәш биргән. Аның бу сәләте турында ишеткәннәр: чарасыз калгач, аңа агылганнар. Хәзрәтнең үгетләренә мохтаҗлар күп булган, күрәсең, кабулханә һич буш калмаган. Халыкның ышануын яулый да, аклый да белгән. Илдә хөрмәт-абруе зур булган. Дөрес, Идел-Урал яклары кабулга килүчеләр саны ягыннан Казахстан белән тиңләшә алмаган. Шулай да, татар-башкорт халыклары тарихында да ул бу чорда шундый ук роль уйнаган дип әйтә алабыз. Андый «имләү» – рухи табиблыкны ул бирегә – шул яшәү рәвеше һәм абруе, шөһрәте аша башкарган.

Байтак кеше өчен ташкын кочагында, өметләрне сүндермичә, чайкалучы бер маяк булган. «Вакыт» газетасындагы некрологта (04.02.1917) Р.Фәхретдинов, Ф.Кәрими кебек олы акыл ияләребез Зәйнулла хәзрәтне «Әтрафның рухани патшасы» дип атаганда, аның мәгърифәтчелеген генә түгел, күбрәк эшчәнлегенең менә бу ягын күз алдында тоталар.

Вакыты шундый – традицияләрнең тәэсире һәм активлыгы зур булган. Ул шуларны истә тотып эш иткән. Тормышка яраклашуны үтә катлауландырган тиңсез иҗтимагый җимерелүләр (революцияләр) хәвефе ябырыла башлаган елларда, ул әтраф халыкларына тормыш фәлсәфәсен өйрәтүче остаз буларак мәйдан тота. Халык, замандашлары аның сабакларын канәгатьләндерерлек дип тапкан, кабул иткән.

Царизм тыкшынуларыннан, империя өркетүләреннән каушамаган, алар өнәмәгән (халыкны рухландыру юнәлешендә) эшчәнлеген дәвам иткән хәзрәт җиңелүгә дучар булган шәхес. Яңа заман таләпләренә яңа югарылыкларда җавап бирә торган «җәдитчеләр», яңа сәяси партияләр, традицияләрне аяктан егарлык итеп читләштереп, алгы сызыкка чыгалар. Вакыт аларны гына куәтли, аларны яклый. Зәйнулла хәзрәт борынгы күренеш кебек, еракта, артта, күләгәдә кала бара. Шәкертләре, мөридләренең яшьрәкләре хәтта хәзрәтне «үги» күрә башлый.

Әле 1902 елларда гына, үзе өчен зур дәрәҗә санап, «мөрид Габделмәҗид әл-Гафури» дип имза куеп, аның улы Һибәтулла үлеменә мәрсия язып бастырган Мәҗит Гафури 1905 елда инде «әллә нәрсә әзләп», Буби, Казан мәдрәсәләренә китеп бара... Хәзрәт яңалыклар алдында каты тунлык та күрсәтми югыйсә.

Мәсәлән, җәдитчеләр – уку-укыту системасын яңартучылар белән, башка ишаннар, карт муллалардан аермалы буларак, ул бәрелешкә керми. Керми генә түгел, искелек яклы (кадимче) көчләрнең җәдитләргә иң катгый һөҗүмгә кучкән чорнарендә, XIX йөз азагында, Зәйнулла хәзрәт «Троицкий голәмәсе» исеменнән җәдитләрне яклап фәтва язып чыга. Шуңа күрә, үзе асылда җәдитче булмаса да, иң күренекле җәдитләр аны үз кешегә санаганнар. Тормышка үзенчәлекле практик мөнәсәбәттә булуы аны мәктәп системасын яңарту зарурлыгын аңлау югарылыгына күтәрә. Гасыр башларыннан ул үзе дә «Рәсүлия»нең башлангыч сыйныфларын җәдитчә укытуга күчерә. «Рәсүлия»нең югарырак сыйныфларын үзе җәдитләштерә алмаячагын аңлаганнан соң, мәдрәсә белән идарә эшен улына һәм яшь (җәдит) укытучыларга тапшыра. Әмма мәдрәсә кирәкләре турында кайгыртуны (димәк, мәдрәсәгә житәкчелекне) ул соңгы сулышына кадәр үз җилкәсеннән төшерми. Үлеме алдыннан үзенең булган акчасына, мөридләрен дә ярдәмгә чакырып, шәһәрдә ике өй сатып алып мәдрәсәгә вакыф иткәне билгеле. Дүрт кузәтүче билгеләп, үзенең бай китапханәсен ул шәһәргә, җәмәгатьчелек файдалануына тапшыра. Шул рәвешчә, үз эшчәнлеген революция башланыр елга китереп, Зәйнулла хәзрәт 1917 елның 2 февралендә вафат була.

Хәзрәтнең үзен дә, халкыбызның үткәндәге тормышындагы тәсаввуф хәрәкәте тарихын да яхшы белгән Р.Фәхретдинов, Ф.Кәримиләр «Вакыт»тагы некрологта, Зәйнулла ишанны безнең төбәктә үткән шәехләрнең иң олысы, күренеклесе, мәшһүре дип күрсәтәләр. Мәгърифәтче буларак та ул мәдәниятебезгә сизелерлек өлеш кертkән, аның даирәсеннән Г.Баттал, М.Гафурилар кебек күренекле кешеләребез чыккан.

**«ИМАН» НӘШРИЯТЫ**

НӘСЫЙХӘТ

# Калеб хәзинәсе

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (салләллаһу галәйһи вәсәллам): «Үз-үзен танып белгән адәм Аллаһы Тәгаләне танып белер», – диде. Кеше кайгы-хәсрәт, байлыкхәерчелек, ярату-күрә алмау кебек сынаулар уза гомер юлында. Белеме һәм гамәлләре күп була. Шулай да инсан әле үз-үзен белә дигән сүз түгел. Аллаһ каршында нинди биеклектәдер бит? Акылыбыз чикле.

Гамәл-гыйбадәтләрне өйрәнеп, кылган гамәлләрең яхшы яки начар, гадел яки гаделсез икәнлегенә эчке тойгылары нинди нәтиҗә ясый? Шуннан чыгып рухи үсеш ясыйммы, әллә тыныч кына «мүк» белән капланамы, әллә инде түбәнгә тәгәриме?

Кешеләр арасында югары дәрәҗәдә булса да, күптәрле белемнәр тупласа да, адәм баласы, Аллаһ җибәргән Пәйгамбәргә (салләллаһу галәйһи вәсәллам), аңа тоташкан остазлар җебенә тотынмаса, хакыйкатьне танып белүе икеле. Пәйгамбәребезнең (салләллаһу галәйһи вәсәллам) «Галим, яки гыйлем алучы бул, яисә гади тыңлаучы бул, әмма дүртенчесе булма. Алайса һәлак булачаксың», дигән сүзләрен истә тотарга тиешбез. Гали (разыйаллаһу ганһу): «Хакыйкатьне танып бел һәм син шул юлдан баручыларны таныйрсың», дигән.

Аллаһка якынаерга омтылган, хакыйкатьне эзләгән, калебен чистарткан кешегә тышкы һәм эчке халәтен югары рухи чистарынуга күтәрү мөмкин. Әбү Хәнифә мәзһәбе бу юлда бөтен мөмкинлекләрне бирә.

Намаз, ураза, хаҗ гамәлләрен кылып та, инсан үсүдән, Аллаһка якынаюдан туктап калуы мөмкин. Пәйгамбәрләрне Аллаһы Тәгалә тәрбияләгән, Үзе юнәлткән. Бу үсешне Бөек Раббыбыз соңгы Пәйгамбәрендә – Мөхәммәд Мостафада (салләллаһу галәйһи вәсәллам) иң югары ноктага җиткергән. Бу рухи үсешне, калебне чистартуны, эчке кичерешләрне аңлауны җаның-тәнең-акылыңны эшкә җигеп, тышкы һәм эчке торышыңны тәртипкә буйсындырып, хакыйкатькә ирешү юлларын Мөхәммәдтән (салләллаһу галәйһи вәсәллам) олуг остазларыбыз безгә җиткергән.



Хәнәфи мәзһәбе тарикатьне төгәл үтәп, бу заман таләпләреннән читкә тайпылмыйча рухи байлыкка ирешү өчен искиткеч мөмкинлекләр бирә. Истигъфар һәм тәүбәне җитәкче итеп, Ислам динен түкми-чәчми безгә җиткергән галимнәребезнең җебенә тоташу мөһим.

Узган гасырның 80-90нчы елларында дин ирегә ачылса да, бу хакта, тарикать төшенчәләре хакында әллә ни сөйләнмәде. Әнием нәсыйхәтләре аша дин-исламга зикер-тәсбихләр аша якынайган инсан буларак, күп кенә кешеләрнең тарикатька карата тискәре мөнәсәбәтенә аптырый идем. Шулай үз-үземә сораулар биреп йөргәндә «Иман» нәшриятында Вәлиулла хәзрәт Якуб (1963-2012) ислам дөньясындагы олы шәехләрнең тәрҗемә китапларын бастырды, ислам тарихында зур урын тоткан суфичылык хакында ачыктан-ачык сөйли башлады. Моңа бик куандым, һәр китапны йотлыып укыдым. Бигрәк тә имам Газали китапларының русчага тәрҗемәләре белән танныштым.

Суфичылык хакында сөйләү тыелган кебек иде бит. Бу аның асылын аңларга теләмәүдән килә дип нәтиҗә чыгардым.

Бу юлга ничек керергә дип эзләнгән еларым иде. 2005 елны Аллаһы Тәгалә мине шәех Мөхәммәд әл Хакканиның укучысы белән очраштырды. Дулкынланудан, шатланудан милләте белән рус булган галимнең исеме дә хәтердә калмаган. Әмма очрашуда үземне кызыксындырган күп сорауларыма җавап алып, бу юлга нинди зикерләр белән якынаерга мөмкинлеген белдем. Ул миңа кайсы зикер-тәсбихны кайчан һәм ничә тапкыр әйтү юлларын аңлатты. Аллаһы Тәгалә үзе сайлаган кешесен Үзе тоташтыра остаз белән һәм теләгән кешесен генә китерә ошбу юлга диюләре хак. Һәм инсаны зикер кылса, остазы кушканча гамәлдә булса, Раббыбыз аңа рәхмәт күзе белән каравын сиздерә.

Еллар үтте. 2014 елны Раббым кабат ачты юлларын. Уфада һәм Казанда остазым дип саналан Мөхәммәд Нәзим әл Хакканиның улы – әүлияләр солтаны, шәех Мөхәммәд Мәхмәт Әзил әл Нәкышбәнди белән күрештем һәм аннан рөхсәт алдым бу юлны дәвам итәргә, теләүчеләргә дә зикер өйрәтергә.

Әлхәмдүлилләһ, бу калебне тәрбияләү юлына басучылар, зикер-тәсбихларга мәхәббәт күзе белән караучылар бар, Раббыбыз үзе сайлаган, үзе теләгән сирәкләрне генә китерә бу хикмәтле юлга.

Динебез инсаннарына әҗер-савап өстәү юлларын бәйнә-бәйнә күрсәтә. Кыямәт көнне гамәлләребез үлчәнгәндә әз генә савап җитмичә, җәннәттән мәхрүм калырга мөмкин. Шуның өчен исән чагыбызда вакытыбызның кадерен белеп, телебезне ошбу зикер-тәсбихларны күп-күп кабатларга күнектерсәк икән.

**ФӘНИЯ ҖӘЛӘЛИЕВА,**
**мөгаллимә, Казан**

ИСЛАМ ТАРИХЫ

# Касыйм хан мәчете, XVI–XIX йөзләр архитектура истәлеге

Касыйм шәһәренең (Рязань өлкәсе) борынгы өлешендә, элекке Хан сарае территориясендә урнашкан. 16 йөз башында Касыйм хан хөрмәтенә төзелә. 1702 елда җимерелә. Зур нигезгә салынган уксыман гөмбәзле, кыска цилиндр рәвешендәге ике ярусы манарасы сакланып калган.

1768 елда мәчет яңадан торгызыла (иске нигездә төзелгән, түбәсе дүрт кыеклы итеп эшләнгән бер катлы, бер заллы бина), 1835 елда икенче каты төзелә (архитекторы билгесез).

Мәчетнең кирпеч бинасы гөмбәз белән тәгәлләнә һәм измә белән сылап шомартыла. Фасадлары һәм интерьеры классицизм стилендә бизәлгән.

Таш манара – шундый типтагы урта гасырлар татар архитектурасының бердәнбер сакланып калган элементы. 1930 елдан бирегә музей эшли.



## АКТУАЛЬ СОРАУЛАРГА ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА ҖАВАПЛАР

**– Хәзер баланың исеме, сәүдәгәрләрнең товары кебек, номерланган журналга языла, заманча техника белән җиһазланган урында компьютер хәтеренә салына һәм туу турында таныклык кәгазе бирелә. Ә нигә борынгыдан килгән йола сакланмый? Ул ничек үтәлә?**

– Мөселман гаиләсендә сабый туганнан соң 40 көн эчендә азан әйтеп исем кушу йоласы бар. ...Пөхтә итеп җыештырылган өйдә сабый иң олы кеше кулына тапшырыла. Ул бала белән кыйблага йөз белән карап баса. Сабый колагына әкрен генә, көч килмәслек йомшак тавыш белән азан әйтә. Сабый, азан һәм бабай... Алар шул мәлдән аерылмас бербөтенгә әйләнә. Ул көнне сабый колагына ягымлы тавыш белән әйтелгән азан моңнары изге рух белән аның миенә нәкыш булып барып урнаша. Азан соңында, өч мәртәбә изгеләндереп әйтелгән исем баланы үз кочагына ала. Шулай итеп, исемсез бала исем иясе була.

«Фатиха» сүрәсе укыла. Йорт эче һәм күңелләр «Фатиха» авазы белән тула! Исеме азан белән изгеләштерелгән һәм исем иясе булган бала әтисенә бирелә. Әтисе исә сабыйны әнисенә тапшыра. Тантана шулай тәмамлана.

Хәзер дә бу йола саклана. Бу исә дини йола гына түгел, ә милли традиция дә, гаилә тантанасы, олы бәйрәм дә. Бу йоланы саклау гаиләгә бәхет, шатлык китерә, аны бозу – зур кимчелек дип саналырга тиеш.

һәрхәлдә, ата-ана балага исемне кичекмәстән, иң яхшысы – бала туганнан соң җиде көн эчендә кушарга тиеш, дип әйтелә.

**– Балага исем кушканда «Сәнә» укыганнан соң ничә тапкыр салават әйтелә? Кайбер урында – 3, кайберсендә 10 мәртәбә, дип күрсәтелгән, бөтенләй күрсәтмәгән чыганаклар да бар.**

– Исем кушкан вакытта шуның кадәр «Салават» укы, дигән сүз юк. Исем кушканда баланың уң колагына, азан укып, исемен әйтәсең, сул колагына камәт укып, исемен әйтәсең дә дога кыласың. Күп кенә кешеләр, нинди дога укырга икән, дип баш ваталар. Доганы ана телендә матур итеп укып кылсаң, бала янындагылар аны тыңлап, аңлап торсалар, бигрәк тә яхшы була.

Мин үзем доганы гел ана телендә кылам. Ничек укуымны кыскача гына әйтеп үтәм: «Йа, Раббем, Син ата-анасының тигезлегеңдә, баланы дүрт яны төгәл, сәламәт, камил акыллы, иманлы итеп яралткансың. Йа, Рабби, әлеге баланы бу гаиләгә, өммәтебезгә олы рәхмәтле вә бәрәкәтле иттерсәң иде. Ата-анасы аны ил-көннәр тынычлыгы вә тәнҗаннар сәламәтлегендә, хәләл, киң, мул нигъмәтләр эчендә иман-Ислам әһеле итеп тәрбияләп үстереп, аның рәхәтен күрүләрен насыйп итсәң иде. Бу баланы, бүген дүрт яны сәламәт итеп китергән шикелле, соңгы сулышына кадәр шул сәламәтлеге белән сакларга Син кадыйрсың. Аңа һәртөрле авырулардан вә бәла-казалардан имин хәлдә, исеме җисеменә муафыйк булып (әлбәттә, исеме мөселманча, матур булырга тиеш) дөньяда гомер итәргә насыйп итсәң иде. Ил-көннәребезгә, милләтебезгә, динебезгә изге хезмәтләр күрсәтүче, шатлык китерүче бер бала булып үссә иде. Бу нәселдән кыяматкәчә фәкать иман-Ислам әһелләре генә килеп торып, Раббем, Сиңа гыйбадәт кылучылар булып, ата-аналарына һәм безләргә хәер-догачылар булып калсалар иде. Хозурыңа да тулы иман белән кайтып, кабер һәм җәһәннәм газапларын күрмәслек дәрәҗәләр бирсәң иде».

**– Балага исем кушканнан соң, ата-анасының саулыгына, малларының иминлегенә багышлап, Коръән укыламы? Аны мәрхүмнәрнең рухына багышларга ярыймы? Кайберәүләр: ярамый, ди.**

– Әлбәттә, нинди генә мәҗлестә булса да, Коръән укып, матур итеп теләкләр теләү тиешле. Гел әйтеп киләбез: Коръән укыганнан соң бер генә кеше, бер генә зат өчен дә дога кылырга кирәкми. Атабыз Адәмнән алып бүгенге көнгә хәтле булган иман әһелләренең рухына ирештерсәң иде, дип, гомуми әйтәсең, аннан соң кемнәрне телисең, шуларны (йорт хуҗаларын, аларның дога өмет иткән мәрхүмнәрен) хаслап әйтеп, дога кыласың.



**– Гәзитләрдә: балага исем кушу, никах укуны ирләр генә башкарырга тиеш, дип язалар. Кайбер якларда аны хатын-кызлар да башкара. Аларга моның дөрес түгеллеген әйтәбез. Әмма алар үз сүзләрендә калалар. Бу дөресме?**

– Исем кушканда азан һәм камәт әйтелә. Хатын-кыз фарыз намазына да камәт әйтми. Хатын-кызга азан, камәт әйтү бурычы йөкләнмәгән, димәк, хатын-кыз, дини яктан бик белемле әбиләр дә, исем куша алмый. Исем кушу – имам эше, ә теләсә кем эше түгел. Исем кушып, никах укып йөрүче, әле шуның өстенә үз гамәлләрен дөрес итеп санаучы хатын-кызларга шуны әйтәм: хакыгыз юк! Хатын-кыз затыннан бернинди пәйгамбәр килгәне юк, хатын-кыз имам була алмый.

**– Кыз бала тугач кыла торган йола нинди?**

– Кыз бала туу турындагы хәбәр малай туу турындагы хәбәр күк кабул ителергә һәм Аллаһка мактаулар укылырга тиеш. Бала өчен эшләнә торган беренче эш – аның колагына азан пышылдау.

**– Бала тугач, ата-ананы котлау, тантана-бәйрәме ничек үткәрелергә тиеш?**

– Ата-ананы бала тууы белән котлау аларның шатлыгына тагын да шатлык өстәү булып санала. Әгәр ата-ананы малай туу белән котлап, кыз туу белән котламасалар, бу – Исламча саналмый.

Котлауга җавап итеп: «Бәлкем, Хак Тәгалә сине дә рәхмәтеннән ташламас, һәм балаңны да», – дигән сүзләр белән рәхмәт белдерергә кирәк.

Гаилә бала тууны ул туганнан соң җиде көн үткәч бәйрәм итә. Бу бәйрәм төп ике өлештән тора – корбан итеп мал чалырга һәм баланың чәчен алырга кирәк.

Кыз бала туу хөрмәтенә бер сарык яки кәҗә, ир бала туу хөрмәтенә ике сарык яки ике кәҗә чалырга киңәш ителә.

Терлекне чалучы кеше: «Бисмилләһ, Әллаһүммә Хадха Минка үә иләйкә» («Аллаһ исеме белән. Ии, Аллаһ, бу фәкать Синең өчен генә эшләнә»), дип әйтергә тиеш.

Терлекнең итен иң яхшысы – өч өлешкә бүләргә кирәк. Берсен өйдә ашарга, икесен туганнарга, күршеләргә һәм ярлыларга өләшергә.

**– Балага үз вакытында исем кушылмаса, нишләргә?**

– Әгәр балага үз вакытында мөселманча итеп, Коръән укытып, азан әйтеп исем куелмаган булса, аны хәзер мәчеткә килеп яки хәзрәтләрдән берәрсен өйгә чакырып эшләргә була.

Бу исә Аллаһ каршында изге хисаплардан санала. Мөселманча дөрес итеп исем кушылмаган балада кайчакларда саташу, куркыну булырга, ул хәтта авырып китәргә мөмкин. Моны күп кенә дөньяви галимнәр дә инкарь итми.

**– Исем кушканда үзара килешә алмасалар?**

– Исем кушканда ата-ана үзара килешә алса, бик яхшы. Әгәр килешә алмыйлар икән, балага исемне ата кеше кушарга тиеш.

**– Исем кушканда баланы ничек яткырырга? Элек муллалар кыйблага каршы салып исем кушалар иде, хәзерге муллалар, киресенчә, кыйблага яны белән куялар.**

– Исем кушканда бала бу рәвешле яисә теге рәвешле ятарга тиеш, дигән тәгаен кагыйдә юк. Ләкин башын үзеңә, аякларын кыйблага куеп, баланы чалкан яткырсаң, хәерлерәк санала.

**Габделхак хәзрәт Саматовның «Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр» китабыннан**

**Газетаны гамәлгә куючы**
«Путь» хәйрия фонды.
Газета Татарстан мөфтияте рөхсәте белән бастырыла

**Редакция шурасы**
Рәисе – Дагыстан республикасы мөфтие, Әхмәд хаҗи АБДУЛЛАЕВ

Татарстан республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

Мәскәү Ислам институты ректоры Дамир ХӘЙРЕТДИНОВ

**Баш мөхәррир**
Азиз МИЧИГИШЕВ

**Мөхәррир**
Ләйлә ХӨСӘЕНОВА

**Баш мөхәррир урынбасары**
Фәрит Батыршин

**Гамәлгә куючы мөхәррир**
Мөхәммәт РӘХИМОВ

**Әдәби мөхәррир**
Рәйсә СӘГАДИЕВА

**Менеджмент**
Абдулсабир АХМЕДОВ

**Веб-версия**
Мөхәммәтрасул ЗАҺИРОВ

**Компьютер төркеме**
Ренат ИСЛАМОВ
Гайсә ОМАРОВ

**Индекс 35888.**
**Подписка в любом почтовом отделении России.**
При перепечатке ссылка обязательна.
Набрано и свёрстано на компьютерной базе газеты «Ас-Салам».
Отпечатано в филиале ГУП МО «КТ» «Мытищинская типография» по адресу: 141009, Московская область, г. Мытищи, ул. Колонцова, 17/2.
Заказ №**335.** Тираж **999** экз.
Подписано в печать (факт) 14.02.2017 в 15:00
(график) 14.02.2017 в 15:00
**Адрес редакции и издателя:**
367015, РД, г. Махачкала, ул. Ярагского, 128.
**E-mail:** assalamweb@gmail.com. **www.**assalam.ru
**Телефоны**
Редакция: +7-904-662-18-75 , +7-928-530-59-70
Подписка и доставка по РТ: +7-987-172-2000
Отдел распространения по РФ: +7-926-222-78-75